КЫЙССА
Һабил белән Кабил кыйссасы
→ 5 БИТ

САБЫЙГА
Айны, йолдызларны күзәтү
→ 9 БИТ

ТАРИХИ МИРАС
Ислам диненең таралуы
→ 10 БИТ

НӘСЫЙХӘТ
Төшенкелеккә бирелү – шәйтаннан
→ 12-13 БИТ

**МАРТ, 2022**
№ 03 (320)

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы

раҗәб – шәгъбан, 1443

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

12+




**Бер хәдистә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан аеның беренче ун көне – рәхмәт, икенче ун көне – мәгъфирәт, өченче ун көне – җәһәннәмнән котылу. Берәү бу айда үзенең малын корбан итсә, Аллаһы аны уттан саклар», – дип әйткән. «Бу айда дүрт әйберне эшләргә тырышыгыз: икесеннән сез Раббыгызның ризалыгына ирешерсез, ә калган икесенә сез үзегез мохтаҗдыр...**

→ ДӘВАМЫ 6 НЧЫ БИТТӘ

ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!



Фото: dumrt.ru

# КУКМАРАДА 1791 ЕЛГЫ МӘЧЕТНЕ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ БАШЛАНДЫ



Фото: dumrt.ru

**18 нче мартта Кукмара районы Мәчкәрә авылында мәдәни мирас объекты булып саналган, 1791-1793 елларда сәүдәгәр Габдулла Үтәмешев тарафыннан салынган Беренче җәмигъ мәчетендә рәсми рәвештә төзекләндерү эшләренә старт бирелде.**

Брифингта Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе Иван Гущин, ТР Президентының эчке сәясәт мәсьәләләре Департаментының дини берләшмәләр белән багланышлар идарәсе башлыгы Альберт Дирзизов, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Азат Гарифуллин чыгыш ясады. Татарстанлылар һәм күпләгән дин кардәшләребез зарыгып көтеп алган, тагын ике елдан реставрацияләнеп, дин кардәшләребезгә тапшырылачак әлеге изге эшкә керешү чарасында Кукмара районы имамнары, авыл халкы, аксакаллар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, журналистлар катнашты. Мәчетне төзекләндерә башлау Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгында, Бәраәт кичәсе көнендә, җомга көнне башлануы белән дә үзенчәлекле.

Мәчкәрә мәчете безнең көннәргә кадәр кулдан язылган бизәкләре белән сакланып калган, татар мәдәнияте архитектурасына караган уникаль һәйкәл булып тора. Мәчет 1920 елларда ябыла, аннары манарасы киселә һәм авыл хуҗалыгы максатларында кулланыла башлый. 2000 елларда анда җирле халык тарафыннан реставрация эшләре башлана, әмма ахырынача тәмамланмый. Мәчетнең тарихын өйрәнү, аны халыкка кайтаруның әһәмиятен җиткерү эшендә Кукмара районы төбәкне өйрәнү музее директоры Ләбүдә Дәүләтшина, Кукмара районы Аксакаллар шурасы җитәкчесе, Мәчкәрә авылы имам-хатыйбы Мөнир хәзрәт Йосыпов үзләренең зур тырышлыкларын куя. Республикабызның Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе Иван Гущин, җыелган халык алдында чыгыш ясап, мәчетнең зур мәдәни мирас объекты булуын билгеләп, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинга бинаны саклап калу буенча башкарылган эшләр өчен рәхмәт сүзләрен җиткерде.

Иван Николаевич төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты саналган иң борынгы (гыйбадәтханәгә хәзер 230 елдан артык) мәчетләрнең берсендә эшләрнең башланып китүен тарихи көн дип атады. Кукмаралылар тарафыннан соңгы 20 ел дәвамында этаплап эшләр башкарылуын, ел саен диярлек хәйрия акчалары һәм бюджет акчалары хисабына әлеге һәйкәлне саклап калу өчен тырышлык күрсәтелүен билгеләп үтте.

– Без бүген төзекләндерү эшләренә генә түгел, «Бергәләп саклыйк» дип исемләнгән проектны оештырып җибәрүгә дә старт бирәбез. Мәчкәрә авылы мәчетен төзекләндерү бары хәйрия акчалары хисабына гына алып барылачак. Һәм безнең бурыч, «Бергәләп саклыйк» проектының максаты – гыйбадәтханәне, дини объектны, борынгы бабаларыбыз күпләгән дини биналар төзегән кебек үк, бөтендөнья белән яңадан торгызу. Моны башкару, һичшиксез, җиңел түгел, һәм бу эштә хәйрия акчаларын җыю, бюджеттан тыш акчалар табу бурычы торачак, һәм мин тарихны торгызу белән шөгыльләнә торган команданың моны башкарып чыгачагына ышанам, чөнки без изге эш башкарабыз. Безнең бурыч – дәвамчыларыбызга, киләчәккә әлеге уникальлекне – уникаль мәдәни мирас объектын җиткерү, – диде Иван Николаевич.

Пресс-турда катнашучы журналистларга мәчетне төзекләндерүгә хәйрия акчаларын җыю өчен махсус сайт булдырылачагы, акчаларны җыю Кукмара районы мөхтәсибәте тарафыннан башкарылачагы игълан ителде. Барлык хәйриячеләрнең исемнәре шулай ук сайтта урын алачак. Акчаларның тотылышы ТР Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты һәм ТР Баш инвестиция-төзелеш идарәсе күзәтчелегендә булачак.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да үз чыгышында тарихи мәчетне кайтаруның мөһимлеген билгеләп үтте: «Бу мәчет – гади генә мәчет түгел. Монда күп галимнәребез укыган. Бу мәчетне бергәләшеп торгызып, намаз укырга, шәкертләребезне укытырга насыйп булсын», – дип теләкләрен җиткерде һәм Рамазан-шәриф ае якынлашуын искәртеп, изге айның фазыйләтләре ту-

рында эчтәлекле вәгазь белән чыгыш ясады. Ул узган Мәчкәрә укуларында Аллаһыдан әлеге бинаның тизрәк мәчет булып эшли башлавын сорап дога кылулары хакында әйтте һәм Мәчкәрә авылы мәчете төзекләндерелеп файдалануга тапшырылганнан соң планнар турында уйларга чакырды.

Рәсми чыгышлардан соң җыелган халык, хәзрәтләр һәм журналистлар бинаның һәр бүлмәсен, сакланышын үз күзләре белән күрде, башкарылачак эшләр буенча җитәкчеләргә һәм белгечләргә сорауларын бирде.

Төзекләндереләчәк мәчет бер манаралы, ике катлы, кирпечтән салынган. Мәчет Казандагы Мәрҗани мәчете үрнәгендә төзелгән.

Кукмара районы Аксакаллар шурасы җитәкчесе, Мәчкәрә авылы имам-хатыйбы Мөнир хәзрәт Йосыпов сүзләренчә, мәчетнең икенче катында урнашкан фарыз залы бүлмәсендә ир-атлар өчен, сөннәт залы бүлмәсендә хатын-кызлар өчен намаз уку залы булдыру ниятләнә. Мәчет берьюлы 200 дин кардәшебезне сыйдыра алачак. Беренче катта музей, балалар һәм олылар өчен уку класслары, ашханә булдырырга уйлыйлар. Шиһабетдин Мәрҗани үз истәлекләрендә телгә алганча, Мәчкәрә мәчете заманында бик зур абруй казанган мәхәллә булган. Һәр ел саен авыл мәдрәсәсендә дистәләгән шәкерт укыган, мәчеттә күренекле дин әһелләре хезмәт иткән. Мәчкәрә мәдрәсәсендә Казан, Уфа, Вятка губерналарының руханилары белем алган, заманының олуг шәхесләре (мәсәлән, атаклы фикер иясе һәм дин белгече Габденнасыйр Курсави, тарихчы-галим Хөсәен Әмирхан һ.б.) укыган.

# Казанда кулъязма Коръәннең бер җөзе язылып бетте


Фото: dumrt.ru

**Татарстан мөфтиятенең кулъязма Коръән язу буенча проектының беренче этабы тәмамланды – каллиграф мосхафның бер җөзен, ягъни Коръән текстының 1/30 өлешен язды. Әлеге эшне башкарып чыгу өчен каллиграфның 70 көн вакыты китте. Иң беренче булып Коръәннең соңгы 30 нчы җөзе язылды. Шулай итеп, яңа мосхаф өчен 20 бит әзер дигән сүз.**

Каллиграф Артур Писаренко сүзләренчә, Коръәннең соңгы өлеше башка җөзләрне язудан иң авыры санала, чөнки соңгы җөз үз эченә, башка җөзләр белән чагыштырганда иң күп һәм иң кыска сүрәләрне һәм аятьләрне ала. 30 нчы җөз 78 нче «Ән-Нәбә» исемле сүрәдән башлана, 36 сүрәдән, ягъни 564 аятьтән тора. Шунысы да мөһим: хафизлар Коръәнне ятлауны соңгы җөздән башлый. Сүрәләрнең күп булуы тәркиб ясауны (ягъни юлларда һәм биттә хәрефләр һәм сүзләрне композицион урнаштыруны) һәм соңыннан хәреф һәм кушылмаларның формаларын исәпләүне катлауландыра.


Казан каллиграфы 30 нчы җөзне язу эшен 12 гыйнвардан 22 нче мартка кадәр башкарды. Эшләү дәверендә, язудан кала, тагын техник әзерлек, язылган битләрне программада электрон нөсхәгә күчерү, экспертлар комиссиясенә тапшыру һәм аларның төзәтмәләрен кертү мәшәкатьләре өстәлде.

Алга таба каллиграф алдында Коръәннең беренче җөзен, ягъни «Фатиха» сүрәсеннән башлап, «Әл-Бәкара» сүрәсенең 241 аятенә кадәр язу максаты тора.

Коръәннең кулъязма мосхафын әзерләү эшен башкарып чыгу өчен Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин 12 белгечтән торган үз җитәкчелегендәге экспертлар комиссиясен туплады. Экспертлар рәтендә – Дубайдан дөньякүләм танылган мөселман галиме, дин әһеле, Дубайның Коръән әзерләү комиссиясе (DIHQA) башлыгы, хафизлыкның иң югары дәрәҗәсенә ия булган шәех Мәэмүн Әр-Рави җәлеп ителде. Әлеге галимнең моңа охшаган проект белән идарә итү тәҗрибәсе бар.

# Нәзарәтнең яңа рәсми аккаунтлары ачылды

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте социаль челтәрләрдә яңа рәсми битләр ачты.**


Фото: yandex.com

Мөфтиятнең аккаунтларына язылучылар Нәзарәт эшчәнлеге һәм Татарстан мөселманнары тормышыннан рус һәм татар телләрендә эксклюзив хәбәрләр белән таныша ала. Нәзарәтнең «Вконтакте» челтәрендәге рус телле рәсми битенә **https://vk.com/dumrt** өстәп, тагын татар телле бит **https://vk.com/dumrt_tatar** булдырылды.

Шулай ук Telegram мессенджерында да Нәзарәтнең берьюлы ике рәсми каналы эшли башлады. Алар «ДУМ РТ» (рус телендәге яңалыклар) һәм «Диния Нәзарәте» (татар телендәге яңалыклар) исеме астында эшли.

Моннан тыш, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте беренче тапкыр Яндекс.Дзен-да рәсми битен теркәде. Язылыгыз!

Роскомнадзор карарына бәйле рәвештә, Инстаграм социаль челтәрендә @dum_rt һәм @dumrt_tatar аккаунтлары, шулай ук Фейсбукта «Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния Нәзарәте» бите вакытлыча туктатылды.

**dumrt.ru** сайтыннан

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 03 (320) март, 2022 | раҗәб – шәгъбан, 1443



Фото: yandex.com

# Уразаның әһәмияте

**Рамазан аенда ураза тоту Ислам диненең өченче нигезе булып тора. Ураза тоту – таң атканнан алып кояш баеганчыга кадәр ашау-эчүдән һәм җенси якынлыктан тыелып торуны аңлата.**

Ураза тоту – иң әһәмиятле гыйбадәт төрләренең берсе. Дөньяда чакта ул безне яман эшләрдән саклый. Ә Кыямәт көнендә Аллаһының гөнаһларыбызны ярлыкавына сәбәпче була, җәһәннәмнән коткара.

### СӘХӘР ҺӘМ ИФТАР

Сәхәр – ураза тотасы көнне таң атканчыга кадәр ашап-эчеп алу. Таң атканчы йокыдан торып сәхәр ашау мөстәхәб булып санала.

Сәхәрне кичтән түгел, ә нәкъ менә таң атуның беренче билгеләре күренә башлар алдыннан ашасаң яхшы була, чөнки бу очракта аның савабы күбрәк. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә болай дип әйткән: «Сәхәрдә ашагыз һәм, шул рәвешле, ураза тотар өчен үзегезне ныгытыгыз. Көндез йоклап алыгыз – бу сезгә төнлә белән тәһәҗҗәд намазына торырга ярдәм итәр» (имам Ибне Мәҗе, «Сыям», 22).

Ураза тотар алдыннан түбәндәге сүзләрне (гарәпчә) укып, тел белән ният кылу мөстәхәб санала:

نَوَيْتُ أَنْ أَصُومَ صَوْمَ شَهْرِ رَمَضَانَ مِنَ
الْفَجْرِ إِلَى الْمَغْرِبِ خَالِصًا لِلّٰهِ تَعَالَى

**«Нәвәйтү ән әсуумә саумә шәһри рамәдаанә минәл-фәҗри иләл-мәгъриби хаалисан лилләәһи тәгааләә».**

*Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә өчен, ихласлык белән таң вакытыннан башлап, кояш батканчыга кадәр Рамазан уразасын тотарга ният кылдым».*

Үз көнен гыйбадәттә, ураза тотып үткәргән мөэмин кешегә ифтар берни белән чагыштырып булмаслык шатлык, Ахирәттә әҗер-савап китерә. Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ураза тоткан мөселман өчен ике төрле шатлык бар: берсе – ифтар вакытында, икенчесе – Аллаһының хозурына килеп баскан вакытта», – дигән (имам Әл-Бохари, «Саум», 20; имам Әл-Мөслим, «Сыям», 163).

Ифтар вакытында авыз ачканда укыла торган дога:

اَللّٰهُمَّ لَكَ صُمْتُ وَبِكَ آمَنْتُ وَعَلَيْكَ
تَوَكَّلْتُ وَعَلَى رِزْقِكَ أَفْطَرْتُ فَاغْفِرْ
لِى يَا غَفَّارُ مَا قَدَّمْتُ وَمَا أَخَّرْتُ

**«Аллааһүммә ләкә сумтү вә бикә әәмәнтү вә галәйкә тәвәккәлтү вә галәә ризкыйкә әфтартү фәгъфирлии йәә гаффәәрү мәә каддәмтү вә мәә әххартү».**

*Мәгънәсе: «Аллаһым, шушы уразамны Синең өчен тоттым, Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. Синең ризыгың белән авыз ачам. Әй, гөнаһларны гафу итүче Аллаһым, минем әүвәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыка».*

### ФИДИЯ

Ураза тотарлык хәле булмаган озак авырган кешеләр һәм олы яшьтәге кешеләр уразаның төшереп калдырылган һәр көне өчен фидия түлиләр. Фидиянең күләме нәкъ фитыр садакасы шикелле хисаплана. Фидияне Рамазан аеның башында да, уртасында һәм ахырында да бирергә була.

Фидияне үзең теләгәнчә бер генә фәкыйрь кешегә бирергә яисә берничә кешегә таратырга да мөмкин. Әгәр мөселман кешесенең фидия өләшергә көченнән килми икән, ул вакытта Аллаһыдан гафу сорарга тиеш.

Әгәр озак авырган кеше сәламәтләнсә, яисә карт кешегә уразасын тотарлык көч-хәл керсә, алар калдырган көннәре өчен уразаны каза итеп тотарга бурычлы. Әлеге очракта бирелгән фидияләре садака булып санала.

### ФИТЫР САДАКАСЫ

Бәйрәм көне җиткәндә бурычлары булмаган һәм нисабка ия булган мөселман кешесе өчен фитыр садакасын бирү вәҗиб булып санала. Фитыр садакасы бирер өчен мал-мөлкәткә тулы ел буе хуҗа булырга яки арта барган мал-мөлкәт булырга тиеш дигән шарт куелмый. Хәлле мөселман өчен фитыр садакасын үзе өчен дә, балигъ булган балалары өчен дә бирү – вәҗиб. Фитыр садакасын азык-төлек белән дә, шуның бәясе кадәр итеп акчалата да бирергә була.

**«Ислам дине нигезләре»** китабыннан

| **1 нче апрель** | **2 нче апрель** | **30 нчы апрель** | **1 нче май** |
|---|---|---|---|
| БЕРЕНЧЕ ТӘРАВИХ | УРАЗАНЫҢ БЕРЕНЧЕ КӨНЕ | СОҢГЫ ТӘРАВИХ НАМАЗЫ | УРАЗАНЫҢ СОҢГЫ КӨНЕ |

**ТӘРАВИХ НАМАЗЫ БАРЛЫК МӘЧЕТЛӘРДӘ 20 РӘКӘГАТЬ ИТЕП УКЫЛА**

2 нче МАЙ – **УРАЗА БӘЙРӘМЕ**

**2022 ЕЛДА НИСАБ, ФИТЫР ҺӘМ ФИДИЯ САДАКАЛАРЫ КҮЛӘМНӘРЕ:**

- ✔ ЗӘКЯТ ТҮЛӘҮ ӨЧЕН НИСАБ КҮЛӘМЕ – **620 000 СУМ** (АЛТЫН БУЕНЧА)
- ✔ ФИТЫР САДАКАСЫ ТҮЛӘҮ ӨЧЕН НИСАБ КҮЛӘМЕ – **58 000 СУМ** (КӨМЕШ БУЕНЧА)
- ✔ ФИТЫР САДАКАСЫНЫҢ МИНИМАЛЬ КҮЛӘМЕ – **150 СУМ**
- ✔ ЗӘКЯТ ЧЫГАРУ МӨМКИНЛЕГЕ БУЛГАННАРГА – **800 СУМ**
- ✔ ФИДИЯ КҮЛӘМЕ – **300 СУМ**

**МӨФТИ КАМИЛ ХӘЗРӘТ СӘМИГУЛЛИННЫҢ МӘКАЛӘЛӘР ЦИКЛЫ**

## «ПӘЙГАМБӘРЛӘР КЫЙССАСЫ»

ДИП АТАЛГАН ЯЗМАЛАР СЕРИЯСЕ



Фото: dumrt.ru

# ҺАБИЛ БЕЛӘН КАБИЛ КЫЙССАСЫ

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Бер ата һәм ана балалары бертуган абый-сеңелләр һәм апа-энеләр булганлыктан, алар кешелекне ничек үрчеткән соң? Шундый зарурлык булганга күрә, ул чорда Аллаһы Тәгалә адәм балалары өчен үзара никахны рөхсәт иткән, ягъни ул вакыттагы шәригать буенча бертуганнарга никах тыелмаган булган. Әмма бер шарт белән: никах игезәк сыңарлар арасында була алмый! Ир балалар үзләреннән алда яки үзләреннән соң туган кыз туганнарына гына өйләнә алган. Кешеләрнең саны билгеле бер күләмгә җиткәч, Нух галәйһиссәлам вакытында, Аллаһы Тәгалә бу кагыйдәне гамәлдән чыгарган һәм бертуганнар арасында никах тыелган.

Адәм галәйһиссәләм белән Хәвва радыяллаһу ганһәнең беренче игезәк балалары булып, Һабил белән Кабил һәм аларның игезәк кыз туганнары дөньяга килгән. Балигъ булгач, Кабил – Һабилнең игезәк кыз туганына, Һабил – Кабилнең игезәк кыз туганына өйләнергә тиеш булган. Ләкин Кабил моңа риза булмаган: аның үзенең чибәр игезәк сыңарына күзе төшкән.

### ТУГАН ТУГАНГА КАРШЫ

Адәм галәйһиссәлам улын үгетләгән, мондый никахның тыелган булуы турында кисәткән, Аллаһының әмерләренә буйсынуны таләп иткән. Ләкин холыксыз, кызу канлы, итагатьсез һәм кечкенәдән үк Һабилдән көнләшеп яшәгән Кабил әтисенә каршы баруыннан туктамаган. Адәм галәйһиссәлам ике улын да үз янына чакырып алып болай дип әйткән:

– Сез икегез дә Аллаһыга корбан китерергә тиешсез. Раббыбыз кемнең корбанын кабул итә, мин бу кызымны шуңа кияүгә бирәм.

Һабил мал үрчетү белән шөгыльләнгән була һәм шуңа да корбанга үзенең иң яхшы көр сарык тәкәсен биргән. Ә игенчелек белән көн күргән Кабил корбанга иң начар бодаен китереп биргән.

Ул вакытларда, әгәр дә Аллаһы корбанны кабул итсә, Ул аңа күктән ут ата торган булган, ә кабул ителмәсә, корбан җирдә ятып калган. Мондый хәл Исраил балалары килеп чыкканга кадәр, җирдә кешеләр ишәеп, алар арасында мохтаҗлар барлыкка килгәнче дәвам иткән. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә бу гамәлне туктаткан.

Риваятьләрнең берсендә, Һабил корбан итеп үз кулларында үстереп тәрбияләгән, җан дусты итеп күргән сарык тәкәсен китергән, дип бәян ителә. Аның белән аерылу ничек кенә авыр булмасын, Аллаһы ризалыгын алу аның өчен барысыннан да кыймммәтрәк булган. Һәм Раббыбыз, билгеле, аның бу олы һәм ихластан тапшырган корбанын кабул итеп ала, һәм сарыгын җәннәткә урнаштыра. Соңыннан, берничә гасыр үтеп, бу сарык тәкәсе әле Ибраһим галәйһиссәламнең улы Исмәгыйль галәйһиссәламне дә үлемнән коткарып калачак. Аларга йолым итеп ирештерелгән хайванны хәтерлисезме? Ул Һабил сарыгы була да инде. Шулай итеп, Һабил үзе дә белмичә, сарыгын корбан китереп, алдагы токымының өзелә язган буынын саклап алып кала.

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

*«Без аңа фидия итеп зур [кыйммәткә һәм гәүдәгә ия булган] бер корбанлык [сарык тәкәсе] бирдек».*

*«Саффәт / Сафта торучылар», 37:107*

Күргәнебезчә, корбан китерү – ул Аллаһыга үзеңнең тугрылыгыңны һәм мәхәббәтеңне мал-мөлкәтең аша белдерү һәм дәлилләү. Ул безгә юмартлык күрсәтергә, Аллаһыга карата булган чиксез сөюебезне, үзебезнең Аңа итагать итүебезне, Раббыбызның чиксез нигъмәтләре өчен рәхмәтебезне белдерергә мөмкинлек бирә. Раббыбызның корбан чалу турында әмере һиҗринең икенче елында ук кабул ителә. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

*«[Шулай булгач] Раббың өчен намаз укы һәм [Аның исеме белән] корбан чал [да, корбан итләрен юксылларга тарат]».*

*«Әл-Кәүсәр / Муллык», 108:2*

Ләкин, Коръәндә шул ук вакытта болай дип әйтелә:

*«Аларның итләре дә, каннары да Аллаһыга ирешәчәк түгел. Аңа сездән бары тәкъвалыгыгыз гына ирешә. Сезне һидаятькә ирештерде дип [«Аллаһү әкбәр» дип] Аллаһыга тәкбир әйтүегез өчен Ул аларны сезгә буйсындырды. [Расүлем!] Күркәм гамәл ияләрен сөендер».*

*«Әл-Хаҗ», 22:37*

Димәк, корбан чалуның асыл мәгънәсе корбан итендә һәм канында түгел, ә чын ихласлык, тәкъвалык, иманда ныклык күрсәтүдә – Аллаһыга итагать итүдә. Һабил мисалы – безгә нәсыйхәт: кеше Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен чалынган корбанының файдасын, һичшиксез, күрәчәк. Әгәр үзе күрмәсә, балалары яки оныкларына куаныч китерәчәк.

*(Дәвамы киләсе санда)*

# Рамазан аен каршы алабыз



Фото: yandex.com

**Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә безгә болай дип хәбәр бирә:**

*«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз буларак] язылды. Бәлки, [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»*

*«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183*

Рамазан аенда һәр көн ураза тоту, ягъни таң яктылыгы җәелгән вакыттан башлап, кояш батканчыга кадәр ашамый, эчми һәм якынлык кылмый тору – балигъ һәм акыллы булган һәрбер мөэмин кешегә фарыз икәнен беләбез.

Аллаһы Тәгаләнең «шәт тәкъвалы булырсыз», дигән сүзләренә игътибар бирергә кирәк. Раббыбыз безгә: «Ураза тотып, әлбәттә, тәкъвалы буласыз», – дип әйтми. Белүебезчә, ураза тоту ашау-эчүдән, якынлык кылудан тыелып тору гына түгел. Уразалы кешенең гайбәт, харамга карау, сүгенү, кеше рәнҗетү, яла ягу, талашу, ялганлау кебек гөнаһлардан тыелуы мөһим.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр кеше бозык сүзләрдән, ялганнан, гайбәттән тыела алмаса, Аллаһы аның ашау-эчүне ташлавына мохтаҗ түгел», – дип әйткән. Шуңа күрә мөселман кешесе Рамазан аена әзерләнгәндә бозык сүзләрдән, ялганнан, гайбәттән тыелырга тырышырга тиеш, әгәр шулай эшләмәсә уразаның әҗерен югалтуы бар. Шулай ук Рамазан аенда җиңелрәк булсын өчен, авыр эшләребезне алдан ук бетереп куярга тырышыйк. Мәсәлән, күптәннән ниятләп йөргән эшләребез бар ди, әйтик, кемгәдер барып килү, нәрсәдер сатып алу, өйдәге кайбер эшләнәсе эшләребез. Әгәр уразалы хәлдә бу эшләр безгә кыенлык тудырасын беләбез икән, аларны йә Рамазан аена кергәнче, йә аннан соң башкара алабыз. Әмма, кыен булмаса, туганнарыбызның хәлен белергә бару, аларны чакырып кунак итү кебек әҗер-саваплы эшләребезне Рамазан аена калдыру, киресенчә, күркәм гамәл булып санала.

Шулай ук Раббыбыз Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйткән:

*«Рамазан ае – аңарда кешеләр өчен һидаять, туры юлны күрсәткән ачык дәлилләр, хакны ялганнан аерган Коръән иңдерелгән [ай]. Сездән берәү Рамазан аена ирешсә, аны ураза тотып үткәрсен».*

*«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185*

Рамазан ае – Коръән иңдерелгән ай. Шуңа да Изге Китабыбызны Рамазан аенда күбрәк укуга игътибар бирсәк иде, чөнки, белүебезчә, аның әҗер-савабы да арттырып бирелә. Калган эшләребезне кайсы вакытта эшләнәсен алдан ук билгеләп куйган кебек, Коръән уку гамәленә дә тиешле игътибар бирик. Тәүлегебезнең бер вакытын Аллаһының Китабын кулыбызга алып укуга, Раббыбызның Сүзләре хакында уйлануга багышлыйк.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Рамазан ае кергәч, җәннәт ишекләре ачыла, җәһәннәм ишекләре ябыла, шәйттаннар баглана», – дигән сүзләрен тапшырган. Шушы хәдистән аңлашылганча, Рамазан аенда Аллаһының рәхмәте иңәр һәм шәйтаннар бикләнер, багланыр һәм ураза тотарга комачауламаслар.

Бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан аеның беренче ун көне – рәхмәт, икенче ун көне – мәгъфирәт, өченче ун көне – җәһәннәмнән котылу. Берәү бу айда үзенең малын корбан итсә, Аллаһы аны уттан саклар», – дип әйткән. «Бу айда дүрт әйберне эшләргә тырышыгыз: икесеннән сез Раббыгызның ризалыгына ирешерсез, ә калган икесенә сез үзегез мохтаҗдыр. Раббыбызның ризалыгына ирештерә торган беренче ике гамәл: «Ләә иләәһә илләллаһ» («Аллаһыдан башка илаһ юк»), кәлимәсен даими рәвештә әйтү һәм истигъфар кылу, ягъни Аллаһыдан гөнаһларыбызны гафу итүен сорау. Ә сез мохтаҗ булган икенче гамәл – ул Аллаһыдан даими рәвештә җәннәтне эстәү һәм җәһәннәмнән сыгыну».

Пәйгамбәребезнең: «Ураза тотучы кешенең ике шатлыгы бар: берсе – авыз ачкан вакытта, ә икенчесе – гөнаһыбыз гафу ителгән хәлдә, Кыямәт көнендә Аллаһы белән очрашканда», – дип әйтелгән күркәм хәдисе бар. Ураза тотучы кешенең ифтар вакытында нинди хисләр кичергәнен беләбез. Бу көне буе нәфесебезне тыя алганга куану хисләре дә, ураза тоту мөмкинлеге биргән Раббыбызга шөкеребез дә, хәләл ризыклар белән тукланыр алдыннан кичергән шатлыгыбыз да. Менә бу ләззәтле мизгелләрне кичерә алсын өчен алдан ук Рамазан аена әзерләник, аның кадерен бөтен тормышыбызга сеңдерик. Рамазан ае гыйбадәте безне сәламәтлегебез белән сынаганга күрә, алдан ук сәламәтлекләребезне кайгыртыйк һәм, иншәАллаһ, Аллаһы Тәгалә изге ниятләребезгә күрә, безгә җиңеллеген Үзе бирер һәм безне әҗер-саваплы итәр.

**Тимергали хәзрәт Юлдашев,**
ТР МДНнең Дәгъват бүлеге белгече,
«Саләх» мәчете имам-хатыйбы



Фото: yandex.com

**Иң югары әхлак үрнәге булып һәм кылырга мөмкин булган иң күркәм һәм бәя биреп бетергесез гамәл булып дини тормышыбызда әдәпләрне үтәү, галәмнәрнең Раббысы Аллаһы Тәгаләнең әмерләренә буйсыну һәм пәйгамбәрләр холкына хас изге гамәлләр кылу тора. Коръәни Кәрим һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте аша Аллаһы Тәгалә безгә әдәпләрне өйрәткән.**

## ТӘҺАРӘТ АЛУ ҺӘМ ПАКЬЛӘНҮ ӘДӘПЛӘРЕ

- ✔ Мисвәк (арак агачы ботаклары) кулланырга
- ✔ Билгеле әгъзаларны юган вакытта тиешле догасын укырга
- ✔ Кылган гөнаһларың өчен тәүбә итәргә
- ✔ Тәһарәт алганнан соң, намазга кадәр, сөйләшмәскә
- ✔ Тәһарәтле булган килеш яңадан тәһарәт алырга (ягъни, икенче намаз вакыты кергәч, яңадан тәһарәт алу, гәрчә әүвәл алган тәһарәт бозылмаган булса да)
- ✔ Мыекларны кыскартырга
- ✔ Тиешле төкләрне кыркырга
- ✔ Тырнак кисәргә
- ✔ Кул һәм аяк бармаклары араларын юарга
- ✔ Борын эчен юарга
- ✔ Кием һәм тәнне пакьләргә

## МӘЧЕТТӘ ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТОТУ ӘДӘПЛӘРЕ

- ✔ Уң аяктан керергә
- ✔ Мәчеткә керер алдыннан аяк киемен нәҗестән чистартырга
- ✔ Аллаһы Тәгаләне зикер итәргә
- ✔ Мәчеттә булучыларга сәлам бирергә
- ✔ Мәчеттә беркем булмаса да, сәлам бирергә
- ✔ Кыйблага таба карап утырырга
- ✔ Үзеңнең хәлең һәм кылган гамәлләрең хакында уйланырга
- ✔ Аз сөйләшергә
- ✔ Беркемне дә ләгънәт кылмаска
- ✔ Тавыш күтәрмәскә
- ✔ Кешеләрне үпкәләтерлек гамәлләр кылмаска
- ✔ Мәчеттә бары тик Аллаһы Тәгаләне зикер итү белән шөгыльләнергә
- ✔ Югалган әйберләрне эзләмәскә
- ✔ Сату-алу белән шөгыльләнмәскә
- ✔ Мәчеттән сул аяк белән чыгарга
- ✔ Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен сорап дога кылырга

## ИГЪТИКӘФ (ФИКЕРЛӘҮ ҺӘМ ГЫЙБАДӘТ КЫЛУ ӨЧЕН ЯЛГЫЗ КАЛУ) ӘДӘПЛӘРЕ

- ✔ Бертуктаусыз (ялыкмыйча) Аллаһы Тәгаләне зикер итәргә
- ✔ Игътибарлы һәм җитди булырга
- ✔ Сөйләшмәскә
- ✔ Бер урыннан торып киткәннән соң, урынны еш алмаштырмаска
- ✔ Нәфес омтылышларына каршы торырга
- ✔ Нәфес омтылган һәрнәрсәдән нәфесне мәхрүм итәргә
- ✔ Нәфесне Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылырга мәҗбүр итәргә

## АЗАН ӘЙТҮ ӘДӘПЛӘРЕ

- ✔ Мөәзин намаз вакыты керү-кермәү мәсьәләләренә үтә дә игътибарлы булырга тиеш
- ✔ Азан әйтелгән вакытта як-якка карамаска
- ✔ Азан вакытында «саләх» һәм «фәләх» кәлимәләрен әйткәндә башны уң һәм сул тарафларга борырга
- ✔ Азанны ашыкмыйча, ачык итеп, ә камәтне – тизрәк әйтергә

## НАМАЗ ӘДӘПЛӘРЕ

- ✔ Үзеңне тыйнак тотарга
- ✔ Аллаһы Тәгалә каршында хөрмәт белдереп, итагать белән басып торырга
- ✔ Аллаһы Тәгалә каршында үзеңнең түбәнлегең һәм зәгыйфьлегеңне белдереп басып торырга
- ✔ Намазны бөтен күңелне биреп укырга
- ✔ Шикле уйларны куарга
- ✔ Намаз вакытында як-ягыңа боргаланмаска, куллар белән артык хәрәкәтләр ясамаска
- ✔ Башны бераз аска иеп, уң кулны сул кул өстенә куярга
- ✔ Коръән укыганда уйланырга
- ✔ Тәкбирне («Аллаһү әкбәр» («Аллаһы бөек» дип әйтү) ихтирам белән әйтергә
- ✔ Рөкүгъ һәм сәҗдәләрне Аллаһы Тәгалә каршында түбәнчелек белән кылырга
- ✔ Аллаһы Тәгаләне бөекләп, тәсбих әйтергә
- ✔ Тәшәһһүдне (намазда утырган вакытта укый торган доганы) Аллаһы Тәгаләне күргән кебек укырга
- ✔ Сәлам биргәндә дулкынланырга
- ✔ Мәчеттән, Аллаһы Тәгалә намазымны кабул иттеме-юкмы, миннән ризамы-юкмы, дип курку катыш борчылу халәтендә чыгарга
- ✔ Аллаһы Тәгалә ризалыгын өмет итеп, намаз кылырга ашыгырга

## КОРЪӘН УКУ ӘДӘПЛӘРЕ

- ✔ Һәрвакыт тәкъва, җитди һәм тыйнак булырга
- ✔ Буш һәм мәгънәсез, начар мәгънәле сүзләр сөйләүдән читләшергә
- ✔ Оялчан булырга
- ✔ Күзләр һәрвакыт кайгылы күз яшьләре белән тулган булырга тиеш

## ДОГА КЫЛУ ӘДӘПЛӘРЕ

- ✔ Йөрәктә курку хисе булырга тиеш
- ✔ Игътибарны тупларга
- ✔ Тышкы кыяфәтең зәгыйфь һәм мохтаҗ булуыңны белдерергә тиеш
- ✔ Фикерләргә
- ✔ Тыйнак булырга
- ✔ Чыннан да мохтаҗ булган әйбереңне сорарга
- ✔ Үзеңнең кемлегеңне (бернинди кыйммәткә ия булмавыңны) танырга
- ✔ Дога кылып мөрәҗәгать иткән Затның бөеклеген танырга
- ✔ Яхшы-күркәм әйбер сораганда, кулларны ачып күтәрергә
- ✔ Аллаһы Тәгаләнең доганы кабул итәчәгенә бөтен күңелең белән ышанырга
- ✔ Аллаһы Тәгалә догаңны кабул итмәс, дип борчылырга
- ✔ Бәла-казаларның үтәчәгенә өметләнергә
- ✔ Дошманлык хисе кичермәскә
- ✔ Ниятләрең дөрес булырга тиеш
- ✔ Дога кылганнан соң куллар белән битне сыпырырга

## ГАЕТ ӘДӘПЛӘРЕ

- ✔ Гает алды кичәсен гыйбадәттә үткәрергә
- ✔ Иртән торып госел алырга
- ✔ Чиста киемнәр кияргә
- ✔ Ислемай сөртергә
- ✔ Һәрдаим тәкбир әйтергә
- ✔ Һәрдаим Аллаһы Тәгаләне зикер итәргә
- ✔ Зур ихтирам белдерергә
- ✔ Тәкбирләр арасында «сөбхәналлаһ» һәм «әлхәмдүлиллаһ» дип әйтү
- ✔ Намаздан соң сөйләшмичә гает хотбәсен тыңларга
- ✔ Рамазан гаетендә мәчеткә барыр алдыннан бик аз гына ашап алырга
- ✔ Мәчеткә бер юл белән барып, кайтканда башка юл белән кайтырга

**Имам Әбү Хәмид Әл-Газалинең**
**«Әдәпләр»** китабыннан

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 03 (320) март, 2022 | раҗәб – шәгъбан, 1443




Фото: dumrt.ru

## КАМИЛ СӘМИГУЛЛИН:

# «Рәсәй милләтен формалаштыруда мөселманнар да катнашты»

**15-17 нче мартта Владикавказ шәһәрендә (Төньяк Осетия-Алания Республикасы) «Гомумрәсәй гражданлык тиңдәшлеген формалаштыру контекстында дини хезмәт һәм дини оешмаларның социаль миссиясе» дип исемләнгән Бөтенрәсәй фәнни-гамәли конференциясе узды.**

Конференция эшендә федераль һәм региональ башкарма хакимият органнарыннан, эксперт берләшмәләреннән 150дән артык вәкил, шулай ук дини берләшмәләр, иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре һәм Рәсәйнең 25 төбәгеннән мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләре катнашты. Пленар утырышта Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты һәм чыгыш ясады. Фәнни форумда Ислам мәгарифе советы исеменнән аның рәисе, Татарстан мөфтие урынбасары, РИИ һәм КИУ ректоры Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшин булды. Шулай ук конференциядә Төньяк Кавказ (Дагыстан Республикасы, Чечня Республикасы мөфтиләре, Төньяк Осетия-Алания Республикасы, Карачаево-Черкесия Республикасы, Ставрополь крае, Адыгея Республикасы һәм Калмыкия Республикасы), Саратов өлкәсе, Кырым Республикасы һәм Севастополь шәһәре мөселман дин әһелләре бар иде. Конференция барышында традицион кыйммәтләрне яклауның һәм Рәсәй халыкларының гражданлык тиңдәшлеген ныгытуның төрле аспектларына кагылышлы мәсьәләләр тикшерелде.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, республика мөселманнары исеменнән фәнни форумда катнашучыларны сәламләп, бүгенге конференция мөһим вакыйга – Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы алдыннан уза, дип билгеләп үтте һәм Төньяк Кавказдагы ислам тарихының тагын да борынгырак тамырлары барлыгын искәртте. Ул ассызыклап узганча, алда торган 1100 еллык та, Төньяк Кавказ җирлегендәге Ислам мәдәниятенең уникаль күпгасырлык истәлекләре мөселманнарның Рәсәйдә төп халыклар дәрәҗәсендә яшәүләрен дәлилли. «Бүген күп динле Рәсәй җәмәгатьчелегенең асылын Ислам динен исәпкә алмыйча белү мөмкин түгел, чөнки бөек Рәсәй милләтен формалаштыруда, шул исәптән, мөселманнар да катнашты. Гомумрәсәй гражданлык тиңдәшлеге турында фикер йөрткәндә боларны истә тоту мөһим», – диде хәзрәт.

Камил хәзрәт Рәсәй Президенты Владимир Владимирович Путинның 2022 елны Рәсәй халыкларының мәдәни мирасы елы дип игълан итүен искә төшерде: «Рәсәйдә Ислам дине гыйлеме беренче чиратта үзебезнең рухи мирасыбызга һәм 11 гасырдан артык яшәгән ислам традицияләренә нигезләнергә тиеш. Борынгы бабаларыбыз безнең өчен бәһасез рухи ядкәрләр калдырган, һәм безнең бурыч – аларны өйрәнү һәм саклау, популярлаштыру һәм яшьләрдә аларга карата кызыксыну тәрбияләү».

Татарстан мөфтие үз чыгышында гражданлык тиңдәшлеге һәм милли-дини үзаң төшенчәләренең бер-берсенә тыгыз бәйләнгән булуын аңлатып, һәр кеше үз Ватанының тулы хокуклы гражданины итеп хис итсен өчен, туган җирендә бабалары гасырлар буе яшәвен һәм хезмәт куюын, үз дәүләтендә чит кеше түгеллеген, башка Ватаны булмавын аңларга тиеш, дип искәртте. «Ватан – ул гаилә, нәсел, милләт белән бәйле төшенчә. Үз мәдәниятеңне белү һәм аны саклау буыннар дәвамчанлыгын сакларга ярдәм итә, ә бу, үз чиратында, җәмгыятьтә тотрыклылык булдырырга, рухи-әхлакый кыйммәтләрне ныгытырга, яшьләрдә үз иленә мәхәббәт тәрбияләргә мөмкинлек бирә», – дип билгеләп үтте ул.

Камил хәзрәт шулай ук Татарстан мөселман уку йортлары тәҗрибәсе белән дә уртаклашты, аларда яшь мөселманнарда гражданлык һәм милли-дини тиңдәшлекне тәрбияләү мәсьәләләренә аерым игътибар бирелүен хәбәр итте: Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте карамагындагы сигез мәдрәсәнең бишесендә белем бирү татар телендә алып барыла, татар халкының тарихы һәм мәдәнияте өйрәнелә, шәкертләр арасында милли-гражданлык үзаңын ныгыту буенча дәрестән тыш тәрбия эшләре алып барыла.

– Төрле мәдәниятләр арасында яшәү, бай рухи мирас һәм уртак Ватаныбызның икътисадын үстерүдә актив катнашу Рәсәй мөселманнарын бүгенге ислам цивилизациясендә иң алдынгы җәмәгатьчелекләрнең берсе итте, – дип нәтиҗә ясады хәзрәт.

**dumrt.ru** сайтыннан



Фото: shutterstock.com

# Айны, йолдызларны күзәтү

**Аллаһы Тәгалә Нух галәйһиссәламне һәм аның белән булган мөэминнәрне коткарганнан соң, җир йөзендә яңа тормыш башлана. Шуңа да Нух галәйһиссәлам, Адәм галәйһиссәламнән соң, кешелекнең икенче атасы дип исәпләнә.**

Нух галәйһиссәламнән соң кешеләр саны арткан, алар шәһәрләр төзеп, җәмәгать булып яши башлаган. Әмма вакытлар үткән саен алар тагын пәйгамбәрләренең әйткән нәсыйхәтләрен онытып, һидаять юлыннан ерагаеп, башка илаһларга табына башлаган. Аллаһы Тәгалә аларга искә төшерер өчен күп пәйгамбәрләр җибәргән, шуларның берсе Ибраһим галәйһиссәлам иде. Ул Бәбил дәүләтенә җибәрелгән. Анда яшәүче кешеләр кояшка, айга, йолдызларга, хәтта үз куллары белән ясалган потларга табына торган иделәр.

Ибраһим галәйһиссәлам пәйгамбәрлек килгәнче бер төнне йолдызларга һәм айга карады да: «Ничек кешеләр илаһ итеп аларга табына ала?» – диде. Төнлә күк йөзен яктыртып торган, ә көндезен күренмәгән ай һәм йолдызлар хакында фикерләп: «Барлыкка килеп, аннары юк була торган ай һәм йолдызлар минем Раббым була алмый», – дип әйтте. Бервакыт Ибраһим галәйһиссәлам нәкъ шул рәвешле кояшны күзәтә: кояш шундый матур итеп күтәрелә һәм көне буе үзенең җылысын, яктылыгын, нурын таратып тора, әмма кич белән акрын гына офыкка төшеп югала. Ибраһим галәйһиссәлам, бу да илаһ була алмый, дип нәтиҗә чыгарды. Ул шушы мәхлүкъларга табынып, аларны илаһ дип санап яшәүче кешеләрне аңлый алмады. Боларның барысын да халык кылучы илаһ бар, дип фикерләп, Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә иман китерде.

Ибраһим галәйһиссәлам бик тә күркәм холыклы, киң күңелле, юмарт кеше иде. Аллаһы Тәгалә, башка пәйгамбәрләргә әйткән кебек, аңа да кешеләрне яхшылык кылуга чакырырга һәм начарлыктан тыярга әмер итте.

Ибраһим галәйһиссәламнең әтисе потка табынучы кеше иде. Ул әтисе өчен бик борчылды. Берьюлы ул: «Ий, әтием, ни өчен син үзеңне ишетми, күрми, сиңа бернинди дә файда китерә алмый торган бу потларга табынасың? Әти, Аллаһы – Бер, Аның тиңдәше юк һәм Аның охшашы юк», – диде. Улының бу сүзләренә ачуы килеп, ул: «Ничек син безнең илаһларны кире кага аласың?» – дип, Ибраһим галәйһиссәламне өйдән куып чыгарды. Әтисенең хаксызлыгына карамастан, ул Аллаһы Тәгаләгә аны ярлыкавын сорап дога кылды.

*Дәвамы киләсе санда, нәни дустым!*

Сәхифәне **Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде





## ТР МДНнең «Хозур» нәшрият йорты «Дневник Рамадана» («Рамазан көндәлеге») дип аталган брошюра нәшер итте

**Безнең көн саен мәгълүмат агымыннан баш әйләнә, ә Рамазан аенда дөнья мәшәкатьләреннән ял итәсе, фарыз һәм нәфел гамәлләребезне күз уңыннан читкә җибәрмичә гыйбадәткә биреләсе килә. Шул ук вакытта без көнкүрешебездәге мөһим мәсьәләләр хакында да истән чыгармаска тиеш. «Дневник Рамадана» вакытны дөрес һәм файдалы рәвештә планлаштыруда алыштыргысыз ярдәмче булачак.**

Брошюраның һәр бите Рамазан аеның 30 көненә багышланган. Ул сезгә бүген Коръәни Кәримнән күпме бит укырга тиеш булуыгызны, Аллаһы Тәгалә каршында әҗер-савапларга ия булыр өчен, нинди изге гамәлләр кыла алуыгызны һәм Раббыбызның исемнәренең мәгънәләрен искә төшерер. Брошюрадагы уңайлы чеклист һәр кылган гамәлегезне билгеләп баруда ярдәм итәчәк.

Без ихластан әлеге басма гыйбадәт кылуда камиллеккә ирешүгә омтылучы һәм вакытларын дөрес итеп кулланырга теләүче мөселманнар өчен файдалы булыр дип өметләнәбез.

**Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан заказ бирергә мөмкин.**
- **Кибет: Казан шәһ., Париж коммунасы ур., 6нчы йорт. Тел.: +7 960 072-74-63;**
- **Склад: Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт. Тел.: +7 (966) 250-00-09;**
- **Интернет-кибет: huzurshop.ru**

РЕКЛАМА. 12+

# МӨХӘММӘД ПӘЙГАМБӘР ҺӘМ ДӨНЬЯДА ИСЛАМ ДИНЕНЕҢ ТАРАЛА БАШЛАВЫ



Фото: shutterstock.com

**Исламның туган җире – VII гасырда борынгы ыруглык җәмгыятенең таркалуы һәм яңа феодал тәртипләр урнаша башлау чорына кергән бүгенге Согуд Гарәбстаны.**

Төрле иҗтимагый катламнар, сәяси фиркалар арасында килеп чыккан кискен каршылыклар белән үрелеп бара торган күчү чоры халыкны үз артыннан ияртеп барырга сәләтле булган кешеләрне тудыра. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм – әнә шундый кешеләрнең иң күренеклесе. Аллаһы Тәгалә тарафыннан пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ирештерелгән Коръәни Кәрим Гарәбстан җирендә таралып утырган күпсанлы, еш кына бер-берсе белән сугышып ятучы кабиләләрне берләштерү көченә ия булган бердәнбер идеологиягә әверелә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дәгъваты нәтиҗәсендә кыска гына вакыт эчендә Гарәбстан халкы мәҗүсилектән Исламга күчеп бетә.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм исән вакытта уңышлы гына башланып киткән дәгъваты аның вафатыннан соң Гарәбстан ярымутравыннан читкә чыга. Йөз ел дәвамында көнбатышта Испания, Марокко һәм Мавританиядән башлап, көнчыгышта Пакыстан, Һиндстан һәм Бангладешка кадәр сузылган, төньякта Урта, Кара, Каспий һәм Арал диңгезләре, көньякта Африка Сахарасы һәм Һинд океаны утраулары белән чикләнгән искиткеч зур территорияләр, шул җирләрдә яши торган халыклар Багдад хакимияте астына эләгәләр.

*Уңышларның нигезе – Коръәни Кәрим идеологиясенең гуманитар асылы, аның гаделлек һәм әхлак нигезләренә корылган тарту көче, дип раслый галимнәр.*

## Көнчыгыш Европада Ислам диненең таралуы. Ибне Рөстә

**VII гасыр урталарында ук Исламның Көнчыгыш Европага, хәзерге Рәсәй җирләренә үтеп керүе башлана. Төньяк Кавказ (бүгенге Дагыстан) территориясендә Багдад хәлифәлегенең төп көндәше – халкы яртылаш диярлек болгарлардан торган Хәзәр каһанлыгы.**

Гарәп-Хәзәр сугышлары йөз елга якын дәвам итә. 737 елда гаскәр башлыгы һәм булачак хәлифә Мәрван бине Мөхәммәдкә Хәзәр каһаны белән солых килешүе төзергә туры килә. Шартнамә буенча Хәзәр каһаны, аның яраннары һәм кул астындагы халыклар, шул исәптән, болгарларның да бер өлеше, җиңүчеләр динен кабул итәләр.

Билгеле булганча, болгарларның Дон елгасы, Азов диңгезе буйларыннан Урта Иделгә күченеп утырулары VIII гасырда башлана. Аларның бер өлеше инде Ислам динендә булгандыр дип уйларга кирәк, чөнки бу төбәкләрдә соңгы елларда болгарлардан калган мөселман зиратлары ачылды.

Танылган фарсы географы һәм тарихчысы Ибне Рөстә тарафыннан 903-912 елларда язылган «Кадерле кыйммәтләр» исемле энциклопедик хезмәттә мондый юллар бар: «Болгарларның күпчелеге Ислам динен тота, авылларында мәчетләр һәм имамнары-мөәзиннәре булган башлангыч мәктәпләр бар… Аларның киемнәре мөселманнарныкына охшаган, зиратлары да мөселманнарныкы кебек». Бу мәгълүматлар, һичшиксез, IX гасыр чынбарлыгын чагылдыра.

*Тагын бер фактны исегезгә төшерәбез: болгар хакиме (әмире) Алмышның 902-908 елларда сугылган көмеш тәңкәләрендә аның мөселманча исеме язылган – Җәгъфәр бине Габдулла. Димәк, ул инде X гасыр башларында ук Ислам диненә күчкән булган.*

**Фаяз Хуҗин,**
археолог, тарих фәннәре докторы

# ХАРБИН ШӘҺӘРЕНДӘ ИСЛАМНЫ КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1000 ЕЛЛЫГЫ БИЛГЕЛӘП ҮТЕЛГӘН

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

**Ерак Көнчыгыш татарлары килеп туган авырлыкларга карамастан, төзү эшләрен төгәлләргә карар кылган. Харбинның яңа имамы Мөнир хәзрәт Хәсибулла өстәмә акчалар туплау өчен, Ерак Көнчыгышның (Кытай, Япония һәм Корея) барлык татар диаспораларын йөреп чыга.**




ХАРБИН МӘЧЕТЕ

Нәтиҗәдә, барысы да төзелеш эшләре тәмамлануын теләгәнгә күрә, зур суммада акча җыела. Һәм 1937 елда төзү эшләре яңадан башлап җибәрелә. 1937 елның 8 нче октябрендә мәчет тантаналы рәвештә ачыла һәм анда беренче җомга намазы уздырыла.

Бу мәчет ике катлы була. Беренче каты ирләр өчен, икенчесе хатын-кызлар өчен каралган. Мәчетне төзегәндә татарлар Болгар архитектура стиленең үзенчәлекләрен исәпкә алырга тырышкан. Мәчетнең эче матур минбәр һәм купшы келәмнәр белән игътибарны җәлеп иткән. Рамазан ае вакытында ярымай неон уты белән яктыртылган.

Мәчет шәһәрнең барлык почмакларыннан күренгән һәм Ерак Көнчыгышта татарларның горурлыгы булып торган. Бу мәчет Болгарда Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы хөрмәтенә төзелгәнгә күрә, халыкта аны «меңъеллык мәчете» дип атый башлаганнар.

1945 елның 20 нче августында Совет гаскәрләре Харбинны ала. Бу татар диаспорасы әгъзаларының репрессиягә эләгүләренә китерә. Җәмәгать һәм мәчет төзелеше эшчәнлеге белән бәйле булган күп документлар юкка чыгарыла.

1945 елның апрель аенда Кытайның халык-азатлык армиясе гаскәрләре шәһәрне ала. 1953 елда мәчет бинасы хакимият тарафыннан Кытай халык армиясенә бушлай тапшырыла. Бу вакытта Харбин шәһәре татар диаспорасының исән-имин калган өлеше Төркиягә һәм Америка Кушма Штатларына күченеп киткән була. Соңрак диаспора дәвамчыларының әгъзалары, мәчетне җирле мөселманнарга кайтарып бирүләрен сорап, вакытвакыт Кытай хакимиятенә мөрәҗәгать итә.

Хәзер мәчет бинасы төзекләндерү эшләренә мохтаҗ. 2018 елда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Кытайда булды. Башкаласы Харбин булган Хэйлунцзян провинциясе делегатлары белән очрашу вакытында ул аның губернаторы Ван Вэньтаога борынгы мәчетне төзекләндерү эшләрендә ярдәм итү һәм төзүчеләр хакында мәгълүмат язылган мемориаль такта урнаштыру үтенече белән мөрәҗәгать итте. Хәзерге вакытта мәчетнең фасадында бу мәчетнең төрек мәчете икәнен белдергән язу тактасы эленгән, гәрчә ул мәчет нәкъ менә татарлар тарафыннан төзелсә дә.




БОЛГАРЛАРНЫҢ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮЛӘРЕНӘ 1100 ЕЛ ТУЛУ ХӨРМӘТЕНӘ АЧЫЛГАН ХАРБИН МӘЧЕТЕ

Фотоның чыганагы: google.com

**Дамир Гайнетдинов язмасы,**
islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 03 (320) март, 2022 | раҗәб – шәгъбан, 1443

# ТӨШЕНКЕЛЕККӘ БИРЕЛҮ – ШӘЙТАННАН



**Еш кына тормыш китергән авырлыклар турында милләтәшләребез белән сөйләшкәндә, кайберләренең авызыннан, Аллаһыга ышанучы мөэмин кеше һичкайчан әйтергә тиеш булмаган сүзләрне ишетергә туры килә. Әйе, рухи тетрәнүләрен, күңелендәгеләрне кеше сабырсызланып теленә чыгарырга ашыкса да, рухи төшенкелеге турында бар кеше дә ишетердәй сөйли икән, димәк, ул үзенең җиңелүе һәм шул хәлдә шәйтанга бирелүе хакында игълан итә. Нигә? Мәкаләдә шул хакта сүз барыр.**

Фото: yandex.com

Билгеле булганча, шәйтан үзенең итагатьсезлеген аклар, балчыктан яратылган һәм Раббыбыз Үзенә сәҗдә кылдырган Адәмнең өмет багларлык бер мәхлүкъ түгеллеген исбатлар өчен, барысын да эшләячәге турында ант иткән. Ул болай ди:

*«Ул әйтте: «Мине аздырганың өчен, мин Синең туры [Ислам] юлыңда, һичшиксез, аларга каршы [киртә булып] утырачакмын. Аннары мин аларга – алларыннан һәм артларыннан, уңнарыннан һәм сулларыннан [вәсвәсәләр бирер өчен, һәр дүрт тарафларыннан] киләчәкмен, һәм Син аларның күпчелеген шөкер итүчеләр буларак тапмаячаксың».*

*«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:16-17*

Күргәнебезчә, шәйтанның адәм балаларын туры юлдан тайпылдыруының беренче һәм төп ысулы – күңелләрендә шөкерсезлек һәм канәгатьсезлек хисләрен кузгату. Димәк, галәмнәр Раббысы белән бәхәсләшүен онытмаган шәйтан кебек мәңгелек хәсрәткә дучар булмас өчен, авырлыкларга зарланып, яшәеше белән канәгать булмаган кеше, иң башта тормышындагы барлык нәрсәләрнең аныкы булмавын, аңа бушлай бирелгәнен, һәм ул үзе билгеләмәгән кануннар буенча яшәвен искә төшерергә тиеш. Бу – шәйтан һәм аның вәсвәсәләренә каршы иң ышанычлы корал һәм иң чыдам калкан! Боларны исендә тотмаган кеше тормышы һәм язмышы белән канәгать булмыйча, дөньяви югалтулары сәбәпле, гел газапланып һәм үкенеп яшәячәк.

### «БҮРЕ КӨТҮДӘН АЕРЫЛГАН САРЫКНЫ ГЫНА АШЫЙ»

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм дә кулыбыздагы нигъмәтләрне ким күрмәвебез, һәм шул сәбәпле чынбарлыктан ерак китмәвебез өчен, тормышны аек акыл белән бәяләргә өйрәткән. Ул болай дип әйтә торган булган: «(Халәтләре) сездән түбән булган кешеләргә карагыз һәм сездән югары булган кешеләргә карамагыз. Бу Аллаһының бер нигъмәтен дә ким итеп күрмәскә ярдәм итәр», – дигән (Имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим, Әхмәд бине Хәнбәл).

Хәлләре безнекеннән тагы да авыррак, һәм, киресенчә, рухи яктан үзебездән көчлерәкләрне күрер һәм алардан үрнәк алыр өчен, мөселман кешесенең гел кеше арасында булуы кирәк. Кеше арасында булу – аны шәйтан тозагы – күңел төшенкелегеннән һәм депрессиядән саклый. Шуңа күрә дә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм мөэмин-мөселманнарны җәмгыятьтән читләшмәскә, иҗтимагый чараларда, һәм бигрәк тә җәмәгать намазларында катнашырга чакырган, чөнки кеше үзенең уйлары, куркулары һәм яшерен теләкләре белән ялгыз калганда шәйтан өчен җиңел ауга әйләнә. Имам Әбү Давыдның җыентыгында килгән бер хәдистә моның турында болай диелә: «Җәмәгать белән бергә бул, чөнки бүре көтүдән аерылган сарыкны гына ашый».

### «АЛЛАҺЫ КЕШЕЛӘРНЕ ЯРАТСА, АЛАРГА СЫНАУ ҖИБӘРӘ»

Әмма кеше күпме сакланса да, Аллаһыга күпме сыенса да, бу дөньяга килгәч, сыналмыйча калуы мөмкин түгел. Көтмәгәндә килеп чыккан проблемалар кешене кайчакта мал-мөлкәтеннән, ирегеннән һәм хәтта сәламәтлегеннән мәхрүм итә. Мондый сынаулар каршында мөэмин кеше үзен ничек тотарга тиеш? Вәгазебезнең башында әйткәнебезчә, бу – кешенең тормышка карашыннан

*«Иң зур сынауларга пәйгамбәрләр һәм алар кебекләр дучар була. Һәр кеше иманына карап сынала. Кешенең иманы никадәр ныклы булса – аңа килгән сынаулар да шул кадәр көчлерәк булыр. Һәм кеше җир йөзендә бөтенләй гөнаһсыз (гөнаһлардан һәм хаталардан чистарынган) хәлдә йөрегәнчегә хәтле бу сынаулар һич туктамас».*

тора. Мөэмин кеше тормышындагы һәрбер нәрсәгә – аңа ата-анасыннан калган мирас һәм Аллаһы Тәгаләдән вакытлыча файдалануга бирелгән әманәт итеп карый, һәм шул сәбәпле, тормышындагы һәрбер вакыйганың нәрсә өчен килеп чыкканлыгын аңлап гомер итә. Коръәннең күп кенә аятьләрендә, җирдәге тормыш шартлары тереклек, һәм бигрәк тә кеше тормышы өчен иң уңайлы рәвештә яратылганлыгы; җирдәге һәрнәрсә кеше һәм аның иминлеге өчен барлыкка китерелгәнлеге турында сөйләнсә дә, кеше бу дөньяга килүгә күп кенә бүтән тереклек процесслары белән тыгыз бәйләнешкә керә. Кайчак, үзе дә белмичә, яки үзеннән тормаган сәбәпләр аркасында, кеше галәмдәге бу төзеклекне бозып, уңайсыз шартларда кала, һәм шуның өчен газап чигә. Бу хакта Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

***«Кайда гына булсагыз да, үлем сезгә [һичшиксез] ирешәчәк, хәтта сез биек итеп салынган ныгытылган [сарай яки] кальгаларда булсагыз да. Әгәр аларга [яһүдиләр белән монафикъларга муллык һәм тынычлык кебек] берәр яхшылык тисә [ул нигъмәтне Аллаһыга нисбәт итеп]: «Бу – Аллаһының Үзеннән» – дип әйтәләр. Әмма [фәкыйрьлек һәм кытлык кебек] берәр начарлык килсә [аны синнән күреп]: «Бу – синнән [һәм синең уңмаганлыгыңнан]», – диләр. [Расүлем!] Әйт: «[Мин бернәрсә дә ярата алмаганлыктан, яратылу ягыннан] Барысы да – Аллаһының Үзеннән». Бу җәмәгатькә ни булды ки, алар [Аллаһы тарафыннан килгән] бер сүзне дә аңлый алмыйлар? [Ий кеше!] Сиңа берәр яхшылык килсә, ул [синең тырышлыгың белән булмыйча] – Аллаһыдан. Әмма сиңа берәр начарлык килсә, [ул да сәбәп булу ягыннан] синең үзеңнән. [Расүлем!] Без сине кешеләргә [илчелек вазифасын йөкләп] бер Расүл салләллаһу галәйһи вә сәлләм буларак җибәрдек [мәгәр бер яратучы, бар итүче итеп җибәрмәдек, алар башларына килгән бәлаләрне синнән дип беләләр]. [Дәгъвәңда] Шаһит буларак Аллаһы җитә.***

*«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:78-79*

Димәк, Аллаһы кешеләргә начарлык теләми һәм кеше тормышындагы һәрнәрсә иминлек һәм бәхетле тормыш өчен яратылган. Дөнья тормышында кеше белән була торган бәхетсезлекләр һәм бәла-казаларга килгәндә, алар кешенең гамәлләре яки гамьсезлеге нәтиҗәседер.

Гомумән алганда, бу шулай, чөнки әгәр тормышка атеист кеше күзләре белән карасак та, Җирдә булган һәрнәрсәнең тереклек өчен яратылуы, тереклек өчен эшләп килүе, һәм тереклекнең дәвам итүе өчен яратылганлыгы күренә. Шуңа күрә иманлы кеше, тормышы һәм язмышы никадәр ачы һәм авыр булса да, зарланырга ашыкмас, һәрнәрсәдә Аллаһының хикмәтен күрергә тырышыр, чөнки ул бу дөньядагы һәрнәрсәнең махсус бер вазифа башкарганлыгына ышанып яшәр. Сынауларга чыдамыйча, тормыш һәм язмышына зарланучы мөэмин Аллаһы Тәгалә тарафыннан үзенә бирелгән рухи дәрәҗәсен генә төшерер.

Бу хакта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Мөэмин кешенең әҗер-савапларының зурлыгы – дучар булган сынаулар һәм авырлыклар зурлыгына тиң. Һәм әгәр дә Аллаһы кешеләрне яратса, Ул аларга сынаулар җибәрә. Сынауларны шөкер итеп кабул иткән кеше Аллаһының ризалыгын, ә язмышын тиргәгән кеше – Аның ачуын табар» (имамнар Әт-Тирмизи, Ибне Мәҗе).

«Иң зур сынауларга пәйгамбәрләр һәм алар кебекләр дучар була. Һәр кеше иманына карап сынала. Кешенең иманы никадәр ныклы булса, аңа килгән сынаулар да шул кадәр көчлерәк булыр. Һәм кеше җир йөзендә бөтенләй гөнаһсыз (гөнаһлардан һәм хаталардан чистарынган) хәлдә йөргәнчегә хәтле бу сынаулар һич туктамас».

## «САБЫР ИТҮЧЕЛӘРНЕ ҖӘННӘТ БЕЛӘН СӨЕНДЕР!»

Димәк, мөэмин кешенең тормышында төшенкелеккә урын булмаска тиеш, чөнки мөэмин кеше гомере буена тереклек һәм яктылык чыганагын – Аллаһыны эзли, Аңа ышана, Аңа омтыла. Мөэмин кеше үлемнән дә, ачлыктан да, матди югалтулардан да курыкмас. Мөэмин кешене бердәнбер борчый торган нәрсә – ул тормышын Аллаһы теләгән рәвешкә китерү, һәм бу дөньядан иманлы хәлдә китү. Коръәндә әйтелгәнчә:

***«Без, һичшиксез, сезне бераз – курку белән, бераз – ачлык белән һәм малларыгызга, җаннарыгызга, [бакча-басуларыгызга афәтләр җибәреп] уңышларыгызга бераз зыян китерү белән сыныйбыз. [Расүлем!] [Сынауларга] Сабыр итүчеләрне [җәннәт белән] сөендер! Берәр бәлагә юлыкканнар: «Һичшиксез, без – Аллаһыныкылар һәм Аңа гына кайтачакбыз!» – дип әйтәләр. Әнә шулар – Раббыларының мәгъфирәтенә һәм рәхмәтенә ирешүчеләр, һәм әнә шулар – [башларына төшкән бәлаләргә сабыр итеп, туры юлга] һидаять табучылар».***


*«Әл-Бәкара / Сыер», 2:155–157*

Тормышларында Аллаһының аятьләрен һәм катнашын күрмичә яшәүчеләрнең тормышы һәрвакыт рухи тетрәнүләр белән тулы булачак, андыйлар турында Коръәндә болай дип әйтелгән:

***«Аллаһының могҗизаларын һәм Аның белән очрашуны инкяр итүчеләр [Кыямәт көнендә] – Минем рәхмәтемнән өмет өзгәннәр. Аларга тилмерткеч газап [әзерләнгән]».***

*«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:23*

**Альберт Кадыйров,**
Казан шәһәре Дәрвишләр бистәсе мәчете мәхәллә әгъзасы, тәрҗемәче




# Җиләкле тау сере

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Холестеринга каршы, составында протеин күп дип соя ярмасы боткасы ашыйм. Кан басымына да әйбәт, зиһенне сакларга да ярдәм итә дигәч, атнага ике тапкыр сөләйман балыгы пешерәм. Авокадо дигән чит илдә үсә торган җимеш тә алып кайта. Монысын алма кебек итеп ашамыйм, салатка салып кына файдаланам. Зәйтүн маеннан өзелгән юк. Аны бик мактый Фәридәм. Кан тамырын тыгылудан саклый, ди. Көн саен бер әстерхан чикләвеге ашыйм. Аннары караҗиләк, кура һәм җир җиләген яман шеш авыруыннан саклый дип әйтә. Йөрәккә файдалы дип, кызыл төстәге фасольне гарниргә кулланам. Шпинат белән петрушка үләнен тутәлдән өзеп алып та ашыйм, яшелчә ашына да салам. Нинди генә салат ясасак та, җитен орлыгы кушам. Менә шулай, кызым өйрәткәнчә тукланып, сиксән дүрт яшемне түгәрәкләдем.

– Аллаһтан әманәт итеп бирелгән гомерне бер дә кыскартасы килми шул, абыстай, яшисе иде әле, – диде Мәликә. – Биш ел элек бер күкрәгемне алдырдым, былтыр икенчесен…

Әнфисә уйчанланып калды, беразз сүзсез торды. Син барысын да беләсең инде, дигәндәй, Нурлыбикәгә карап алды:

– Башта мине дә химия белән дәвалап карадылар. Бүлмәсенең ишеген ачып кергәндә дә, чыкканда да күңелемнән: шушы авырудан терелеп, үз аягымда йөри алсам, халыкка дин хезмәте күрсәтер идем дип теләдем. Аллаһ ихлас ниятемне ишетте. Шуннан бирле биш йөзгә якын йортта Коръән укыдым, дүрт йөз мәет юып озаттым. Болар мактаныр өчен сөйли торган гамәл түгел, дөрес итеп аңлагыз, шатланып әйтәм. Ниятең көчле булса, Аллаһ Раббыбызның яман чирне җиңәргә дә Үзенең ярдәмен салуын белдерәсем килә.

Әнфисә абыстайның йомшак тавыш белән үзе турында берсен дә яшермичә сөйләвенә Мәликәнең күңеле күтәрелде, йөзенә алсулык җәелде.

– Коръән укырга бик теләсәм дә, өйрәнә алмадым шул, абыстай, – диде. – Яшьрәк чакта заманы андый түгел иде, хәзер күз комачаулый. Укый башласаң, хәрефләр биешә. Син, сөбеханалла абыстай, шушы яшеңдә укый алгач, бик әйбәт.

Әнфисә башын селкеп елмаеп куйды һәм:

– Тәннең һәр әгъзасын майлап торырга кирәк, – диде. – Күзем иртән эренләмәсен өчен, кичтән җитен мае сөртеп ятам. Зәйтүн мае да әйбәт, анысын күзгә генә түгел, битеңә сылап куйсаң да, тән тиресе языылып кала. Күзгә бал салуның шифасын күрәм.

Аларның сүзен колак салып тыңлап утыручы Гайникамал да күзен челт-челт итеп йомып алды.

– Аны ничегрәк итеп саласы соң, абыстай? Нормасы дим…

– Бер чәй калагы чиста балны өч чәй калагы кайнап чыккан җылымса су белән болгатасы һәм шуны күнгә бер-ике тамчы тамызсаң, файдасы шулкадәр күп, – дигәч, Мәликә:

– Изге кешенең янында утырсаң да, изгелеге тияр, диләр. И, күпме файдалы киңәшләр бирдең, абыстай, – диде.

– Саулыгыңны яшьтән сакла дисәләр дә, көч-куәт кайнап торганда дөнья артыннан куасың шул. Тормыш иткәндә барысы да кирәк. Куып тотам дип чаба-чаба тәмам хәлдән таясың. Ирем авырый башлагач, аңа шулкадәр ярдәм итәсем, терелтәсем килде. Ул үлгәч, озак та үтмәде, минем бугазда да шеш барлыкка килде. Иң газиз кешең авырганда, аны-моны уйлап тормыйсың, җәфаланганын күреп, чирен үзеңә алырдай буласың, – дип тирән сулап куйды, бит уртасы кып-кызыл булып чыкты. – Аз гына дулкынлану да ярамый, кан басымы югары күтәрелә. Яшел чәй эчәм, ул нормада тотарга ярдәм итә, – дигәч, Гайникамал чәй ясап китерде.

– Дару эчәргә тырышмыйм, – диде Әнфисә. – Коръән укыганда күзләрем арып китсә, каты чәйне мамыкка тамызып, ун-унбиш минутка күзгә куеп ятып торам. Шул җиңеләйтеп җибәрә. Баш авыртканда укроп орлыгы төнәтмәсенең файдасын күрәм, шуны аз-азлап берничә тапкыр эчкәч, авыртуы басыла.

Айбикә өстәлгә самовар чыгарды.

– Әнфисә апа, син үзең дә табиб булып беткәнсең ич, күпме файдалы киңәш бирдең, – диде һәм барысының да чәйләрен яңартты.

– Туганнан алып мәңгелек йортка күчкәнче, тормыш кешене үзе өйрәтә, Айбикә акыллым…

---

## Һидаятьтә…

*Аллаһы биргән барлык*
*кануннардан*
*Ислам дигән күркәм юл чыга.*
*Бирче, Раббым, күркәм*
*сабырлыклар*
*Шушы юлдан барган юлчыга.*

*Бирче, Раббым, тәүфыйк,*
*истикамәт*
*Адашмыйча үтик шул юлдан.*
*Барасы җир таныш булмаса да*
*Хәзерлеге кирәк шул алдан.*

*Без мосафир гына бу җиһанда*
*Ә кунакка күбрәк игътибар*
*Шуңа син дә кануннарны*
*үтәп,*
*Ислам дигән күркәм*
*юлдан бар.*

**Габделхәким Фәсхиев**

## ДҮШӘМБЕ-ЯКШӘМБЕ

| | |
|---|---|
| **07:00** | Онлайн-мәдрәсә |
| **07:30** | «Рухуль-Бәйан» |
| **07:35** | Мәслихәт |
| **07:55** | Татарлар тарихы |
| **08:35** | «Иң гүзәл исемнәр» |
| **08:45** | Имамнан сорыйк |
| **09:30** | Дин турында |
| **10:00** | Гыйбрәтле хикәяләр |
| **10:15** | Хәдис дәресләре |
| **10:35** | «Ислам мәдәниятенең алтын гасыры» |
| **10:45** | «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы |
| **10:55** | «Сүз эчендә хикмәт бар» |
| **11:05** | Намазга өйрәник (ирләр өчен) |
| **11:30** | Вәгазь вакыты |
| **12:00** | Азан |
| **12:05** | «Узнаем у имама» |
| **12:50** | Исламская теология |
| **13:20** | «Энциклопедия для маленьких мусульман» |
| **13:25** | «Шекер Ходжа» анимационный фильм |
| **13:35** | «Совершенные женщины» |
| **13:50** | «Хузур-вояж» Антон Кротов белән |
| **14:00** | «Так поступал Пророк» |
| **14:15** | «Мастерская вкуса» |
| **14:30** | Фәнни-танып-белү фильмы |
| **15:00** | Нәфис сериал |
| **16:00** | Онлайн-мәдрәсә |
| **16:30** | «Рухуль-Бәйан» |
| **16:35** | Мәслихәт |
| **16:55** | Татарлар тарихы |
| **17:35** | «Иң гүзәл исемнәр» |
| **17:45** | Имамнан сорыйк |
| **18:30** | Дин турында |
| **19:00** | Гыйбрәтле хикәяләр |
| **19:15** | Хәдис дәресләре |
| **19:35** | «Ислам мәдәниятенең алтын гасыры» |
| **19:45** | «Шөкер хуҗа» анимацион фильмы |
| **19:55** | «Сүз эчендә хикмәт бар» |
| **20:10** | Намазга өйрәник (хатын-кызлар өчен) |
| **20:30** | Вәгазь вакыты |
| **21:00** | «Узнаем у имама» |
| **21:45** | Исламская теология |
| **22:15** | «Энциклопедия для маленьких мусульман» |
| **22:20** | «Шекер Ходжа» анимационный фильм |
| **22:30** | «Совершенные женщины» |
| **22:45** | «Хузур-вояж» Антон Кротов белән |
| **22:55** | «Так поступал Пророк» |
| **23:10** | «Мастерская вкуса» |
| **23:25** | Фәнни-танып-белү фильмы |
| **23:55** | Нәфис сериал |
| **00:55** | Гыйбрәтле хикәяләр |
| **01:10** | Коръәни Кәрим укылышы (мәгънәви тәрҗемәләр белән) |


## ТР МДНнең «Хозур» нәшрият йорты

# «365 көн догада»

## дип аталган китап нәшер итте

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дога – ул гыйбадәт», – дип әйткән.**

Без дога кылу үрнәкләрен Коръәни Кәримнән, Расүлебезнең сөннәтеннән укып беләбез. Безнең максат – доганы үзебезнең юлдашыбыз итү, чөнки һәр вакытта да, һәр очракта да Раббыбызга дога белән мөрәҗәгать итә, Аңа сыена, Аннан ярдәм сорый алабыз. Бу мөселман кешесе өчен бирелгән олуг нигъмәт.

«365 көн догада» дип исемләнгән әлеге китапта тормышыбызның һәр очрагына кагылышлы булган догалар тәкъдим ителде. Биредә без дога кылу әдәпләре, шартлары, тәртипләре белән дә таныша алабыз. Шулай ук китапта зикерләр, салаватлар, мөбарәк кичәләрдә, айларда кылына торган догалар һәм Коръән укыгач багышлый торган догалар да урын алган. Хезмәт тормышыбызны догалы итүдә сәбәпче булыр һәм һәркем өчен файдалы булыр дип өметләнәбез.




**Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан заказ бирергә мөмкин.**

- **Кибет: Казан шәһ., Париж коммунасы ур., 6 нчы йорт. Тел.: +7 960 072-74-63;**
- **Склад: Казан шәһ., Газовая ур., 14 нче йорт. Тел.: +7 (966) 250-00-09;**
- **Интернет-кибет: huzurshop.ru**

РЕКЛАМА. 12+



**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**

Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;

ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе **Булат МӨБАРӘКОВ;**

Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**

ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррирләр: **Хәләфетдинова Л. Г., Юлдашева А. И.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Шәйхетдинов А. Х.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**НӘШИР:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт).
Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.

Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.

Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә. Заказ №2727.
График буенча – 25 нче март 21.00, гамәлдә – 21.00 сәгатьтә кул куелды.

Газетага ярты елга язылу бәясе – 140, 40 сум.
Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 29 нчы март көнне таратыла.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

## АПРЕЛЬ 2022 / КАЗАН

| Көн | Көн исеме | ИРТӘНГЕ НАМАЗ | | Кояш чыга | ЗӘВӘЛ | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ / ИФТАР | ЯСТҮ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | | |
| 01 | Җом | 03:00 | 03:44 | 05:14 | 11:47 | 12:00 | 16:11 | 18:21 | 20:10 |
| 02 | Шим | 02:57 | 03:42 | 05:12 | 11:47 | 12:00 | 16:13 | 18:23 | 20:12 |
| 03 | Якш | 02:53 | 03:39 | 05:09 | 11:46 | 12:00 | 16:14 | 18:25 | 20:15 |
| 04 | Дүш | 02:50 | 03:37 | 05:07 | 11:46 | 12:00 | 16:16 | 18:27 | 20:17 |
| 05 | Сиш | 02:46 | 03:34 | 05:04 | 11:46 | 12:00 | 16:17 | 18:29 | 20:20 |
| 06 | Чәрш | 02:42 | 03:31 | 05:01 | 11:45 | 12:00 | 16:19 | 18:31 | 20:23 |
| 07 | Пәнҗ | 02:39 | 03:29 | 04:59 | 11:45 | 12:00 | 16:20 | 18:33 | 20:26 |
| 08 | Җом | 02:35 | 03:26 | 04:56 | 11:45 | 12:00 | 16:22 | 18:35 | 20:28 |
| 09 | Шим | 02:31 | 03:24 | 04:54 | 11:45 | 12:00 | 16:23 | 18:37 | 20:31 |
| 10 | Якш | 02:28 | 03:21 | 04:51 | 11:44 | 12:00 | 16:24 | 18:39 | 20:34 |
| 11 | Дүш | 02:24 | 03:19 | 04:49 | 11:44 | 12:00 | 16:26 | 18:41 | 20:37 |
| 12 | Сиш | 02:20 | 03:16 | 04:46 | 11:44 | 12:00 | 16:27 | 18:43 | 20:40 |
| 13 | Чәрш | 02:16 | 03:14 | 04:44 | 11:44 | 12:00 | 16:29 | 18:45 | 20:43 |
| 14 | Пәнҗ | 02:12 | 03:11 | 04:41 | 11:43 | 12:00 | 16:30 | 18:47 | 20:46 |
| 15 | Җом | 02:08 | 03:08 | 04:38 | 11:43 | 12:00 | 16:31 | 18:49 | 20:49 |
| 16 | Шим | 02:03 | 03:06 | 04:36 | 11:43 | 12:00 | 16:33 | 18:51 | 20:52 |
| 17 | Якш | 01:59 | 03:04 | 04:34 | 11:43 | 12:00 | 16:34 | 18:53 | 20:55 |
| 18 | Дүш | 01:55 | 03:01 | 04:31 | 11:42 | 12:00 | 16:35 | 18:55 | 20:58 |
| 19 | Сиш | 01:50 | 02:59 | 04:29 | 11:42 | 12:00 | 16:37 | 18:57 | 21:02 |
| 20 | Чәрш | 01:46 | 02:56 | 04:26 | 11:42 | 12:00 | 16:38 | 18:59 | 21:05 |
| 21 | Пәнҗ | 01:41 | 02:54 | 04:24 | 11:42 | 12:00 | 16:39 | 19:01 | 21:08 |
| 22 | Җом | 01:36 | 02:51 | 04:21 | 11:42 | 12:00 | 16:41 | 19:03 | 21:12 |
| 23 | Шим | 01:32 | 02:49 | 04:19 | 11:41 | 12:00 | 16:42 | 19:05 | 21:15 |
| 24 | Якш | 01:26 | 02:47 | 04:17 | 11:41 | 12:00 | 16:43 | 19:07 | 21:19 |
| 25 | Дүш | 01:21 | 02:44 | 04:14 | 11:41 | 12:00 | 16:45 | 19:09 | 21:22 |
| 26 | Сиш | 01:16 | 02:42 | 04:12 | 11:41 | 12:00 | 16:46 | 19:11 | 21:26 |
| 27 | Чәрш | 01:10 | 02:39 | 04:09 | 11:41 | 12:00 | 16:47 | 19:13 | 21:30 |
| 28 | Пәнҗ | 01:04 | 02:37 | 04:07 | 11:41 | 12:00 | 16:48 | 19:15 | 21:33 |
| 29 | Җом | 00:58 | 02:35 | 04:05 | 11:40 | 12:00 | 16:50 | 19:17 | 21:37 |
| 30 | Шим | 00:51 | 02:33 | 04:03 | 11:40 | 12:00 | 16:51 | 19:19 | 21:41 |

- 1 нче апрельдә ястү намазыннан соң беренче тәравих намазы укыла
- 2 нче апрель – 1 Рамазан – Рамазан ае башлана, уразаның беренче көне
- 30 нчы апрельдә – соңгы тәравих намазы